**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4693**
**12.07.2021**

Яр Чаллы шәһәренең «Заря» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, шәһәр Уставының 41 статьясы, Шәһәр Советының 2008 елның 19 ноябрендәге 35/7 номерлы карары белән расланган Муниципаль предприятиеләрнең һәм учреждениеләрнең хезмәт күрсәтүләренә тарифлар билгеләү турында карарлар кабул итү тәртибе хакында нигезләмәнең 5 пункты, Башкарма комитетның 2013 елның 1 ноябрендәге 6561 номерлы карары белән расланган Муниципаль унитар предприятиеләрнең һәм муниципаль учреждениеләрнең хезмәтләренә тарифларны исәпләү тәртибе хакында нигезләмә нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәренең «Заря» спорт мәктәбе» муниципаль автономияле учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләргә тарифларны кушымтада каралганча расларга.
2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 12 июлендәге
4693 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәренең «Заря» спорт мәктәбе» МАУ тарафыннан
күрсәтелә торган хезмәтләргә
тарифлар

| № т/б | Хезмәтнең исеме | Үлчәү берәмлеге | Бәясе, сум |
|---|---|---|---|
| 1. | Уен залы хезмәтләре | сәгать | 1400,00 |
| 2. | Чаралар/ярышлар үткәрү | сәгать | 1700,00 |
| 3. | Кече зал хезмәтләре | сәгать | 400,00 |
| 4. | Өстәл теннисы уйнау өчен хезмәтләр күрсәтү | сәгать | 150,00 |
| 5. | Бадминтон уйнау өчен хезмәтләр күрсәтү | сәгать | 300,00 |
| II. Өстәмә хезмәтләр | | | |
| 1 | Сәламәтләндерү үзәге хезмәтләре | сәгать | 500,00 |
| 2 | Спорт инвентарен прокатка бирү | 1 шартлы берәмлек | 100,00 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева